ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Приказ** **Боерык**

02.08.2018 г. Казань № 202-од

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен раслау турында

2009 елның 17 июленнән “Норматив-хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 172-ФЗ номерлы Федераль канун, 2010 елның 26 февраленнән “Норматив-хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары, 2017 елның 29 июненнән “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте әгъзаларының норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертизаны тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмгыять фикерен исәпкә алу турында” УП-575 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Боерыгы, 2009 елның 24 декабреннән “Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 883 номерлы, 2017 елның 15 августыннан “2017 елның 29 июненнән “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте әгъзаларының норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертизаны тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмгыять фикерен исәпкә алу турында” УП-575 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Боерыгын тормышка ашыру чаралары турында” 580 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән тәңгәл килеп боерам:

1. Кушылып бирелгән Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен расларга.

2. Бу боерыкны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының структур бүлекчәләр җитәкчеләренә җиткерергә.

3. Әлеге боерык, аны рәсми бастырганнан соң, 10 көннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлүе артыннан тикшерүне рәис урынбасары Р.Г. Шарафутдиновка тапшырырга.

Рәис Ф.С.Батков

02.08.2018 елдан 202-од номерлы
Татарстан Республикасының Биологик
ресурслар буенча дәүләт комитетының
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибе.

I. Гомуми кагыйдәләр.

1.1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына (алга таба – актлар) һәм норматив хокукый актлар проектларына (алга таба – акт проектлары) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) актларына һәм актлар проектларына, Дәүләт комитетының актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүне кертеп һәм коррупциягә каршы экспертизаның нәтиҗәләрен күздә тотып, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза Дәүләт комитетының эшләнә торган актлар проектларына хокукый экспертиза үткәргәндә һәм Дәүләт комитетының кабул ителгән актларын мониторинглаганда, аларда коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максаты белән үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны яки конфиденциаль характердагы мәгълүматларны үз эченә алучы норматив-хокукый актларга, норматив-хокукый актларның проектларына карата үткәрелми.

1.4. Көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган актларга карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелми.

1.5.Дәүләт комитетының актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүне оештыруның төп принциплары:

1) актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү мәҗбүри;

2) башка норматив хокукый актлар белән элемтәдә норматив хокукый актны (норматив хокукый актлар проектларын)бәяләү;

3) актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләренең нигезләнүе, объективлыгы һәм тикшерелүе;

4) актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыручы затларның компетентлыгы;

5) актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздырганда, Дәүләт комитетының, ә шулай ук аның вазыйфаи затларының граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итүе.

1.6. Коррупциягә каршы экспертизага кергән актлар һәм актлар проектлары, норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү журналында теркәлә (алга таба – Журнал) (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта).

## II. Дәүләт комитетының актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза

2.1. Дәүләт комитетының актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза хокукый эш буенча алдынгы киңәшче, ул булмаган очракта дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөдире белән уздырыла ( алга таба – вазыйфаи зат).

2.2. Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен актлар һәм актлар проектлары, әлеге акт аның инициативасы буенча кабул ителгән структур бүлекчәсе җитәкчесе белән (акт проектын эшләгән өчен җаваплы зат), вазифаи затка җибәрелә.

2.3. Актлар һәм актлар проектлары коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен, шулай ук Комитет рәисе белән җибәрелергә мөмкин.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза акт теркәү Журналында теркәлгәннән соң, ун көн эчендә үткәрелә.

Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган актларга карата үткәрелми.

2.5. Коррупциягә каршы экспертизаны гамәлгә ашыру процессында вазыйфаи зат кирәк булган очракта, коррупциягә каршы экспертизада кызыксынган структур бүлекчәләрдән һәм вазыйфаи затлардан өстәмә материаллар яки мәгълүмат сорарга һәм алырга хокуклы. Сорала торган материаллар һәм мәгълүмат вазифаи затка, сорау кергәннән соң , өч көн эчендә бирелергә тиеш.

2.6. Вазыйфаи зат экспертизага бирелгән актта (акт проектында), коррупцияле факторлар булу яки булмауны билгели.

2.7. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча бәяләмә төзелә, анда түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

экспертизага бирелгән акт реквизитлары (акт проектының исеме);

акт керү датасы (акт проекты);

экспертиза уздыру датасы;

экспертиза уздыру өчен нигез;

актта (акт проектында) коррупцияле факторлар булу яки булмау;

коррупцияле факторлар булган актның (акт проектының) конкрет кагыйдәнамәләре;

коррупциялекне бетерү өчен, хокукый нормаларының әйтелешен үзгәртү яки аерым нормаларны төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр.

2.8. Коррупциягә каршы экспертиза акты (акт проекты), нәтиҗәләре буенча төзелгән, вазыйфаи зат тарафыннан әзерләнгән, һәм имзаланган бәяләмә, направившему әлеге актны (акт проектын) коррупциягә каршы экспертизага биргән затка җибәрелә.

2.9. Әгәр коррупциягә каршы экспертизага бирелгән актта коррупцияле факторлар ачыкланса, аның инициативасы буенча кабул ителгән, структур бүлекчә җитәкчесе, актны алгач, коррупциягә каршы экспертиза предметы булып торган актка үзгәрешләр кертү турында яисә үз көчен югалтуын тану турында, өч көн эчендә норматив хокукый акт проектын әзерләргә һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен вазифаи затка җибәрергә бурычлы.

Күрсәтелгән үзгәрешләр кертү турындагы акт проектында коррупцияле факторлар булмаган очракта, бәяләмә вазыйфаи зат белән, акт аның инициативасы буенча кабул ителгән структур бүлекчә җитәкчесенә һәм акт проекты белән кызыксынган структур бүлекчәләр җитәкчеләре визалары белән Дәүләт комитеты рәисенә имза кую өчен җибәрелә.

2.10. Әгәр, экспертизага җибәрелгән акт проектында коррупция факторлары юк икән, акт проектын эшләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе , акт проекты белән кызыксынган структур бүлекчәләр җитәкчеләре визалары белән,Дәүләт комитеты рәисенә имза кую өчен җибәрә яки актны кызыксынган әгъзаларга һәм оешмаларга яраштыруга юнәлтүне тәэмин итә.

2.11. Әгәр экспертизага җибәрелгән акт проектында коррупция факторлары табылса, акт проектын эшләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, бәяләмә алганнан соң, барлык җитешсезлекләрне өч көн эчендә бетергә һәм эшләнеп беткән акт проектын вазифаи затка кабат коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җибәрергә бурычлы.

Кабат коррупциягә каршы экспертиза үткәрү вакыты өч көннән дә артмаска тиеш.

Эшләнеп беткән акт проектында коррупция факторлары булмаган очракта, бәяләмә вазыйфаи зат белән имзалана һәм акт проекты белән кызыксынган структур бүлекчәләр җитәкчеләре визалары белән, Дәүләт комитеты рәисенә имза кую өчен җибәрелә.

Эшләнеп беткән акт проектында коррупция факторлары булган очракта, вазыйфаи зат Дәүләт комитеты рәисенә бәяләмәне юнәлтә. Дәүләт комитеты рәисе бәяләмәне, анда ясалган нәтиҗәләр белән туры килеп, гамәлгә ашыру өчен, структур бүлекчә җитәкчесенә юнәлтә.

Структур бүлекчә Җитәкчесе барлык җитешсезлекләрне өч көн эчендә бетерергә һәм акт проекты белән кызыксынган структур бүлекчәләр җитәкчеләре визалары белән, Дәүләт комитеты рәисенә имза кую өчен җибәрергә бурычлы.

2.12. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда чагылыш таба.

## III. Актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү

3.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып, “Интернет” челтәрендәге Дәүләт комитетының рәсми сайтында http://ojm.tatarstan.ru (алга

таба –сайт) урнаштырылган, Дәүләт комитетының рәсми басылып чыккан актлары һәм актларның проектлары килә.

3.2. Дәүләт комитетының актларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен, Дәүләт комитетында актлар һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы вазыйфаи зат, акт проектын журналда теркәгәннән соң бер эш көне дәвамында, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен Дәүләт комитеты адресын (шул исәптән Дәүләт комитетының электрон почта адресын)күрсәтеп , акт проектын сайтта урнаштыра, ә шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау көнен күрсәтә.

3.3. Сайтта урнаштырган актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты -кимендә биш эш көне .

3.4. Дәүләт комитетына кергән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза акты (акт проекты) (алга таба - бәяләмә) бәяләмә нәтиҗәләре буенча, актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы Дәүләт Комитетының структур бүлекчәсенә, тикшерү өчен җибәрелә.

3.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсе нәтиҗәләре, тәкъдим рәвешендә бирелә һәм Дәүләт комитеты белән мәҗбүри каралырга тиеш. Ачыкланган коррупция факторларын бетерү юлы турында тәкъдимнәр бирелмәгән очрактан тыш, бәяләмәне алганнан көннән Календарь көннәрдә санала торган 15 көнлек срокта , Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе кергән бәяләмәне карый һәм бәйсез коррупциягә каршы экспертиза уздырган юридик яки физик затка нигезле җавап җибәрә.

3.6.Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырганда ачыкланган коррупция факторлары, Дәүләт комитетның актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе белән, Тәртипнең 3.5. пунктында күрсәтелгән вакытта бетерелә.

3.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза белән бирелгән бәяләмәдә күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәннән һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, Дәүләт комитетының акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе, Дәүләт комитеты актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы затка, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәләрне теркәп акт проектын кабат карау өчен бирә.

Кабат карау өч көнлек срокта гамәлгә ашырыла.

3.8. Әгәр актта коррупция факторлары ачыкланса, әлеге актны әзерләгән Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе, Дәүләт комитетында бәяләмәне теркәгәннән соң 3 көн эчендә, актка үзгәрешләр кертү буенча яки аны үз көчен югалткан дип тану турында чаралар күрә.

3.9. Дәүләт комитеты, аның белән эшләнгән актларда һәм актлар проектларында коррупция факторлары булуны раслый торган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, Дәүләт комитеты кануннар белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән актларны, актлар проектларын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризасызлыгы

нигезләнгән аңлатма язуын теркәп, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрә.

3.10. Эшләп чыгаручы тарафыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының канун чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына кертелә торган, аның белән эшләнгән федераль канун проектларында, Татарстан Республикасы кануннары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты боерыклары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциоген факторлар булуны турында раслый торган, коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре белән (шул исәптән бәйсез) килешмәгән очракта, эшләп чыгаручы, күрсәтелгән норматив-хокукый актларның проектларын тикшерү өчен, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризасызлыгы нигезләнгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентында билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

## IV. Норматив-хокукый актларның проектлары буенча иҗтимагый фикер алышу

4.1. Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнә торган норматив-хокукый актларның проектлары буенча иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итә.

4.2. Иҗтимагый фикер алышу максатында норматив-хокукый актларның проектлары, аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм иҗтимагый фикер алышу өчен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте әгъзаларының норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру өчен , бердәм региональ интернет-портал булып билгеләнгән, Татарстан Республикасының Рәсми порталында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырыла (алга таба -Мәгълүмат ресурсы).

4.3. Иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен, Мәгълүмат ресурсында, гражданнарның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган норматив-хокукый актлар проектлары урнаштырыла.

4.4. Иҗтимагый фикер алышу максаты белән урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил иткән яки конфиденциаль характердагы мәгълүматларны үз эченә алган норматив-хокукый актлар проектлары,

актларны (аларның структур берәмлекләрен) үз көчләрен югалткан дип тану турында норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы Президенты белән билгеләнгән, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары белән йөкләгән эшләү вакыты, иҗтимагый фикер алышу (Мәгълүмат ресурсында урнаштырганнан соң кимендә биш эш көне) өчен минималь сроктан ким, норматив-хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яки чыгымнарына йогынты күрсәтүче норматив-хокукый актлар проектлары,Татарстан Республикасы

бюджетын үтәүне ын, тәэмин итү белән бәйле норматив хокукый актлар проектлары;

дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салуга кагылышлы норматив-хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын, кануннар үзгәрешләре белән тәңгәл китерүче норматив хокукый актлар проектлары;

суд карарларын, прокурор мөнәсәбәте актларын, тикшерү-хисап әгъзалары күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру максаты белән әзерләнгән норматив-хокукый актлар проектлары;

дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентлар проектлары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары;

Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын туктатып тору турында норматив хокукый актлар проектлары.

4.5. Иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен, норматив-хокукый актлар проектларын урнаштырганда, проект аның инициативасы белән эшкәртелгән, структур бүлекчә, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр юнәлтү өчен адресын(шул исәптән электрон почта адресын), ә шулай ук иҗтимагый фикер алышуның башлану һәм тәмамлану вакытын күрсәтә.

4.6. Эшләп чыгаручы белән, норматив хокукый актларның иҗтимагый фикер алышу өчен билгеләнгән вакыт, Мәгълүмат ресурсында урнаштырганнан соң кимендә биш эш көне булырга тиеш.

4.7. Проект аның инициативасы белән эшләнгән, структур бүлекчә, иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча, норматив хокукый акт проектын эшләп бетерү турында карар кабул иткән очракта, эшләнеп беткән норматив хокукый акт проекты, иҗтимагый фикер алышу максатыннан шулай ук урнаштырыла.

4.8. Норматив хокукый акт проектын мәгълүмат ресурсында Урнаштыру, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә
1нче кушымта

**Коррупциягә каршы экспертизага тапшырылган норматив-хокукый актларны һәм норматив-хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналы**

| № | Актның (акт проектының) экспертизага тапшырылу датасы | Актны (акт проектын) эшләгән структур бүлекчә исеме | Актның (акт проектының) исеме | Экспертиза үткәрү вакыты | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе | Структур бүлекчә белгече белән бәяләмәне алу датасы һәм аның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә
2нче кушымта

Коррупция факторлары булу турында бәяләмә

___________________________________________________________
(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән, 2009 елның 17 июлендәге “Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 172-ФЗ номерлы Федераль канун , 2010 елның 26 февралендәге “Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә, коррупция факторларын ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатларында

___________________________________________________________
(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.

Тапшырылган ______________________________________________

(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының исеме)
түбәндәге коррупциоген факторлар ачыкланды___________________________
(коррупциоген фактор төрләре күрсәтелә)

Ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү өчен түбәндәгеләр киңәш ителә_______________________________________________________
(коррупциоген факторларны бетерү ысуллары күрсәтелә)

| ______________________ | ______________ | _______________________ | _______ |
|---|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (инициаллар, фамилия) | (дата) |

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә
3нче кушымта

**Коррупция факторларының юклыгы турында бәяләмә**

________________________________________________________________
(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән, 2009 елның 17 июлендәге “Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 172-ФЗ номерлы Федераль канун, 2010 елның 26 февралендәге “Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә, коррупция факторларын ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатларында

________________________________________________________________
(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.
Актның керү датасы:
Экспертиза уздыру датасы:
Тапшырылган _____________________________________________________

(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

коррупция факторлары ачыкланмады.

____________________ _____________ _____________________ _________
(вазыйфа (имза) (инициаллар, фамилия) (дата)